| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2018 Балык Бистәсе штп.пгт. № 200пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл җирлекләрендәге торак бинаныторак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2017 елның 24 гыйнварында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Башкарма комитетының 11пи номерлы карары белән расланган Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актны 2017 елның 29 декабрендәге "“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль законның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә мөрәҗәгать итүченең бердәм гариза бирүе аркылы берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүмөмкинлеген беркетү өлешенә үзгәрешләр кертү хакында” гы 479-ФЗ номерлы Федераль законга тәңгәлләштерү максатларында,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының2010 елның 2 ноябрендәге ”Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы 880 номерлы карары,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында”гы 96пи номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл җирлекләрендәге торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2017 елның 24 гыйнварында Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе районы Башкарма комитетының 11пи номерлы карары белән расланган Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1.5 пунктының өченче абзацында “муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос белән,” сүзләреннән соң “шул исәптән 2010 елның 27 июлендәге“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210-ФЗ номерлы законның 15.1 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә,” сүзләре белән тулыландырырга;

1.2)5 бүлекнең атамасын “,күпфункцияле үзәкнең,күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

1.3)5.1 пунктында:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;”;

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүченең күпфункцияле үзәкнең,күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәленә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирүе мөмкин шул очракта, әгәр карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;”;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) муниципаль хезмәт күрсәтүгә отказ бирү, әгәр аны кире кагуга нигезләр федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүченең күпфункцияле үзәкнең,күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәленә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирүе мөмкин шул очракта,әгәр карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;”;

7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең,күпфункцияле үзәк хезмәткәренең 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтүләргә мөмкинлек бирү нәтиҗәсендә бирелгән документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яки

мондый төзәтүләргә билгеләнгән срокларны бозуы.Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүченеңкүпфункцияле үзәкнең,күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәленә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирүе мөмкин шул очракта,әгәр карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;”;

түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча белән тулыландырырга:

“8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яки бирү тәртибен бозу:”:

түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктча белән тулыландырырга:

“9)әгәр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан туктатып торуга нигез каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүгә мөмкинлек бирүне туктатып тору.Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүченеңкүпфункцияле үзәкнең,күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәленә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирүе мөмкин шул очракта,әгәр карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;”;

1.4.5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 5.2. Шикаять язмача формада кәгазь мәгълүмат йөрткечтә, электрон формада Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкнең оештыручысы булып торган (алга таба – күпфункцияле үзәкнең оештыручысы) ачык хокукый белем бирү дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына), шулай ук 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә ( гамәл кылмавына) шикаятьләр югарыгы органга (ул булганда) бирелә яисә, ул булмаса, турыдан-туры Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карала.Күпфункцияле үзәкнеңкарарларына һәм гамәлләренә ( гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәкнең җитәкчесенә бирелә.Күпфункцияле үзәкнеңкарарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәкнең оештыручысына яки Татарстан Республикасының норматив хокукый акты тарафыннан вәкаләт бирелгән вазыйфаи затка бирелә.2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларныңкарарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр бу оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта белән күпфункцияле үзәк аша “Интернет”мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтын (www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша “Интернет”мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтын (www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин. 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша “Интернет”мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.”:

1.5))5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.3.Башкарма комитетка, күпфункциональле үзәккә, күпфункциональле үзәкнең оештыручысына,2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарыгы органга (әгәр ул булса) кергән шикаять теркәлгән көненнән алып унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә Башкарма комитетның,күпфункциональле үзәкнең,күпфункциональле үзәкне оештыручының,2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның кире кагу очрагына, мөрәҗәгать итүченең документларын кабул итүдә яисә җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүдә яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата бирелгән шикаятьне – ул теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә.”;

1.6) ) 5.4 пунктында:

1 пунктчаны “муниципаль хезмәткәрнең” сүзләреннән соң “күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең,2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең,”сүзләре белән тулыландырырга;

3 пунктчаны “,күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең,2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның

16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

4 пунктчаны “муниципаль хезмәткәрнең” сүзләреннән соң “күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең,2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең” сүзләре белән тулыландырырга;

1.7) 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.7.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару,муниципаль хезмәт күрсәтүләргә мөмкинлек бирү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтү, түләтү Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары,муниципальнорматив хокукый актлар тарафыннан каралмаган акча средстволарын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару формасында канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача формада һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.”;

1.8)5.8 пунктында “бирелгән” сүзен “бирелгән хезмәткәр”сүзләренә, “җибәрә” сүзен “җибәрәләр” сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет”мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет”мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүнеүземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы В.И.Токранов